КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2024 ел, 25 март г.Казань № б-640

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 29 сентябрь, б-2160 нчы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$. Бу боерыкка теркәлгән Татарстан Республикасында төп игътибарны клиентларга бирүне кертүне оештыру моделен расларга.»;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасында төп игътибарны клиентларга бирү стандартларын кертү чаралары планында («юл картасында»):

1 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «1. | Оештыру чаралары | | | |
| 1.1. | Татарстан Республикасында төп игътибарны клиентларга бирүне кертү турында мәгълүмат кампаниясен алып бару планын раслау | 30.12.2024 | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, республика башкарма хакимият органнары | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы тарафыннан расланган медиаплан |
| 1.2. | Татарстан Республикасында төп игътибарны клиентларга бирүне кертүне оештыру моделен раслау | 25.03.2024 | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы»; |

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «2. | Тормыш хәлләре | | | |
| 2.1. | Татарстан Республикасының тормыш хәлләре исемлеген раслау | 15.03.2024 | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2.2. | Татарстан Республикасының тормыш хәлләре буенча максатчан торышлар образларын формалаштыру | 15.04.2024 | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | Татарстан Республикасының тормыш хәлләре буенча максатчан торышлар образлары |
| 2.3. | Татарстан Республикасының тормыш хәлләрен җентекләп өйрәнү һәм гамәлгә ашыру буенча «юл карталарын» формалаштыру | 01.05.2024 | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | Татарстан Республикасының тормыш хәлләрен җентекләп өйрәнү һәм гамәлгә ашыру буенча «юл карталары» |
| 2.4. | Татарстан Республикасының тормыш хәлләре буенча максатчан торышлар образларын раслау | 30.05.2024 | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | республика башкарма хакимият органы боерыгы |
| 2.5. | Татарстан Республикасының тормыш хәлләрен җентекләп | 30.05.2024 | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан | республика башкарма хакимият органы боерыгы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | өйрәнү һәм гамәлгә ашыру буенча «юл карталарын» раслау | | Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | |
| 2.6. | 2024 елда Татарстан Республикасының тормыш хәлләре буенча максатчан торышларны гамәлгә ашыру | 02.12.2024 | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2024 елда Татарстан Республикасының тормыш хәлләре буенча максатчан торышларны гамәлгә ашыру турында «Россия Федерациясе Хөкүмәте каршындагы Аналитик үзәк» автоном коммерциягә карамаган оешмасына хисап |
| 2.7. | 2025 елда Татарстан Республикасының тормыш хәлләре буенча максатчан торышларны гамәлгә ашыру | 01.12.2025 | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2025 елда Татарстан Республикасының тормыш хәлләре буенча максатчан торышларны гамәлгә ашыру турында «Россия Федерациясе Хөкүмәте каршындагы Аналитик үзәк» автоном коммерциягә карамаган оешмасына хисап»; |

әлеге боерыкка Татарстан Республикасында төп игътибарны клиентларга бирүне кертүне оештыру моделен (боерыкка теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 29 сентябрь, б-2160 нчы
боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 25 март, б-640 нчы
боерыгы редакциясендә)

# Татарстан Республикасында төп игътибарны клиентларга бирүне кертүне оештыру моделе

Татарстан Республикасында төп игътибарны клиентларга бирүне кертүне оештыру моделе төп игътибарны клиентларга бирүне кертүдә катнашучылар исемлеген һәм аларның функцияләрен билгели.

## I. Төп игътибарны клиентларга бирүне кертү өчен җаваплы зат

1.1. Татарстан Республикасында төп игътибарны клиентларга бирү принципларын һәм стандартларын кертү өчен җаваплы зат (алга таба – төп игътибарны клиентларга бирүне кертү өчен җаваплы зат) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән билгеләнә.

1.2. Төп игътибарны клиентларга бирүне кертү өчен җаваплы зат:

төп игътибарны клиентларга бирүне кертү сәясәтен һәм юнәлешләрен билгели;

төп игътибарны клиентларга бирүне кертү барышын контрольдә тота;

Татарстан Республикасының төп игътибарны клиентларга бирү стандартларын кертү чаралары планын (алга таба – «юл картасын») гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында «Россия Федерациясе Хөкүмәте каршындагы Аналитик үзәк» автоном коммерциягә карамаган оешмасына хисаплар тапшыра.

## II. Төп игътибарны клиентларга бирүне кертү буенча вәкаләтле республика башкарма хакимият органы

2.1. Төп игътибарны клиентларга бирүне кертү буенча вәкаләтле республика башкарма хакимият органы (алга таба – вәкаләтле орган) – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы нигезендә республика башкарма хакимият органнары эшчәнлегенә төп игътибарны клиентларга бирү принципларын кертүне координацияләү һәм контрольдә тоту өчен җаваплы итеп билгеләнгән республика башкарма хакимият органы.

2.2. Вәкаләтле орган:

Татарстан Республикасында төп игътибарны клиентларга бирүне кертүдә методологик булышлык күрсәтүне тәэмин итә;

Татарстан Республикасында төп игътибарны клиентларга бирүне кертү чараларын гамәлгә ашыру буенча республика башкарма хакимият органнары эшен координацияли;

республика башкарма хакимият органнары эшчәнлегенә төп игътибарны клиентларга бирү принципларын кертүне контрольдә тотуны тәэмин итә;

«юл картасын» гамәлгә ашыру өчен җаваплы булып тора.

## III. Республика башкарма хакимият органнары

3.1. Республика башкарма хакимият органнары төп игътибарны клиентларга бирү стандартларын кертү кысаларында аларга беркетелгән вәкаләтләр буенча башкарма-күрсәтмә функцияләрен гамәлгә ашыра.

3.2. Республика башкарма хакимият органнары:

республика башкарма хакимият органында төп игътибарны клиентларга бирү стандартларын кертү чаралары планын («юл картасын»), «юл картасын» билгеләнгән срокларда гамәлгә ашыра;

республика башкарма хакимият органында төп игътибарны клиентларга бирү стандартларын кертү чаралары планын («юл картасын»), «юл картасын» гамәлгә ашырганда ведомствоара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасында төп игътибарны клиентларга бирүне кертү нәтиҗәләренә үз вакытында ирешүне тәэмин итү буенча тәкъдимнәр ясый;

республика башкарма хакимият органында төп игътибарны клиентларга бирү стандартларын кертү чаралары планын («юл картасын»), «юл картасын» гамәлгә ашыру турында хисаплар төзи һәм аларны төп игътибарны клиентларга бирүне кертү өчен җаваплы затка җибәрә.

---